**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «11» июленнән № 47-357

2023 елда «2023-2030 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру һәм 2024 елга бурычлар турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы А. И. Бутинаның 2023 елда «2023-2030 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру һәм 2024 елга бурычлар турында мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы А. И. Бутинаның 2023 елда «2023-2030 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру һәм 2024 елга бурычлар турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә:

- балалар бакчаларында федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә торган, шул исәптән сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дә, шартлар тудыру эшен дәвам итәргә;
- районда гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты (алга таба - ГДББС) таләпләре нигезендә төп белем бирү программаларын үзләштерүнең сыйфатын мониторинглау системасын булдырырга;
- белем бирүнең сыйфаты һәм мәгариф оешмалары эшенең нәтиҗәләре турында мәгълүматның мөмкин кадәр ачык һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итәргә;
- белем бирү сыйфатын бәяләүдә тышкы дәүләт- иҗтимагый ролен көчәйтү һәм эчке һәм тышкы бәяләүнең үзара оптималь хезмәттәшлегенә ирешергә;

-кулланучыларның белем бирү хезмәтләрен сайлый алу,  белем бирүнең эчтәлегенә һәм технологияләренә төзәтмәләр кертүне тәэмин итә торган хосусый белем казанышлары турында мәгълүмат җыю һәм анализлау системасын булдырырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов